**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Зур Кукмара авыл җирлеге**
**муниципаль берәмлеге**

# КАРАР

**22 ноябрь, 2023 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске -Йорт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2023 елның 22 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының беренче, икенче, өченче этаплары нәтиҗәсе буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

1. Юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
2. Иске Йорт авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.
3. Иске Йорт авылындагы чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү
4. Урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.
5. Балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
6. Су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын буяу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру; су суырту башнясын сатып алу һәм урнаштыру.
7. Иске Йорт һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект - смета документациясен эшләү
8. Янгын гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү
9. Иске Йорт авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү
10. Яңа суүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү
11. Саклау, ремонтлау, коймалар төзү, зиратларны төзекләндерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 124 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 65 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 64 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 1 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске- Йорт авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыененың нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске -Йорт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

1. Юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

2. Иске Йорт авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

3. Иске Йорт авылындагы чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү

4. Урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.

5. Балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

6. Су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын буяу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру; су суырту башнясын сатып алу һәм урнаштыру.

7. Иске Йорт һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект - смета документациясен эшләү

8. Янгын гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү

9. Иске Йорт авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү

10. Яңа сусүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү

11. Саклау, ремонтлау, коймалар төзү, зиратларны төзекләндерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зур Кукмара
авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәнәфиев